Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү турында

2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 10 апрелендәге 316 номерлы «2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру турында»гы карарын, 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 июлендәге 523 номерлы «Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру турында» карарын утәү йөзеннән КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Чүпрәле муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе килешүе буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясен төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча район комиссиясе турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча район комиссиясенә ярдәм итәргә;

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының (Татарстанстат) район структур бүлекчәсенә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле соратып алына торган документлар һәм мәгълүмат бирергә;

тиешле авыл җирлекләре территориясендә яшәүче гражданнарны авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итәргә;

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының (Татарстанстат) район структур бүлекчәсенә 2015 елның 1 августына кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләре, шәхси торак төзелеше һәм (яки) авыл хуҗалыгы терлекләре баш саны булган авыл торак пунктлары халкы исемлекләрен ачыклау юлы белән 2015 елның 1 августына кадәр тапшырырга;

2015 елның 1 августына кадәр хуҗалык китапларының тулылыгын һәм дөреслеген тикшерүне төгәлләргә.

5. Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетына:

телефон элемтәсе һәм мебель белән җиһазландырылган саклана торган бинаны, авыл хуҗалыгы исәпкә алу объектлары турында белешмәләр җыю һәм авыл хуҗалыгы исәбен алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклау өчен, шулай ук транспорт чараларын бирергә;

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрдән максатчан файдалануны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының район бүлегенә авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыючы затлар эше өчен яраклы биналарны саклауны, исәпкә алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклауны, шулай ук авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыючы затларның эш иминлеген тәэмин итәргә тәкъдим итәргә;

7. «Росреестрның ФКП» ФДБУнең Чүпрәле бүлегенә Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Территориаль органының (Татарстанстат) район структур бүлекчәсенә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җанисәп объектлары исемлекләрен төзү өчен кирәкле күчемсез милек объектлары турында белешмәләр алуда ярдәм итүне тәкъдим итәргә;

8. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2015 елның 1 августына кадәр федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының (Татарстанстат) район структур бүлекчәсенә 2015 елның 1 гыйнварына кадәр крестьян (фермер)

хуҗалыклары һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләрен (алга таба төгәлләштереп) тапшырырга кирәк.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы И.В. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль район Башлыгы: А.В. Шадриков

Хәйруллина Э. Ж.
2-20-50

1 нче кушымта Чүпрәле
муниципаль районы
Башлыгының 2015 елның
«__»________ __
номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча район комиссиясе
СОСТАВы

| | |
|---|---|
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, комиссия рәисе |
| Әхмәтов Эмиль Салют улы | Чүпрәле муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| Мөхәммәтҗанов Ирек Вазыйх улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Чүпрәле муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| Низаева Фидания Әгъләметдин кызы | Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының район структур бүлекчәсенең әйдәп баручы белгеч-эксперты (Татарстанстат), комиссия секретаре (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Сарафанов Алексей Иванович | Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Вәлиуллин Ирфат Зәкиулла улы | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча); |
| Абязов Радмил Саяр улы | Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенең Чүпрәле филиалы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сибагатов Марат Вячеславович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Чүпрәле районындагы бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Хәнҗәрова Эльмира Рифкат кызы | «Җир кадастр палатасы» федераль дәүләт учреждениесенең бүлек башлыгы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Нуртдинова<br>Равия Хәмит кызы | Чүпрәле муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Җамалетдинова<br>Резидә Ринат кызы | «Туган як» газетасы мөхәррире (килешү буенча) |
| Ракипов<br>Илдар Альберт улы | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге начальнигы; |
| Иматдинов<br>Айрат Әхәт улы | "Чүпрәле район дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ башлыгы (килешү буенча); |
| Карсаков<br>Николай Александрович | "Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДБУ директоры (килешү буенча); |
| Тугушев<br>Алмаз Абзал улы | Чүпрәле муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча). |

Гомуми бүлек башлыгы: Г.Ф. Хәлиуллов

2 нче кушымта Чүпрәле
муниципаль районы
Башлыгының 2015 елның
«__»________ __
номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен оештырылган.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү, үткәрү, аның нәтиҗәләрен эшкәртү һәм бастырып чыгару буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләгәндә һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен карый.

5. Комиссия хокуклы:

Чүпрәле муниципаль районы (шул исәптән авыл җирлекләре) җирле үзидарә органнары вәкилләрен Чүпрәле муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында тыңлау;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә

органнарыннан 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча материаллар соратып алырга;

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу мәсьәләләре буенча авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр җибәрергә;

комиссия утырышына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затларын, иҗтимагый-дини берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен, галимнәрне, белгечләрне чакырырга;

комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итү белән бәйле проблемалар буенча аерым тәкъдимнәр эшләү өчен вакытлыча эш төркемнәре булдыру.

6. Комиссия составы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

7. Комиссия комиссия рәисеннән, ике урынбасардан, комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, комиссиянең эш планнарын раслый, комиссия составын аныклау һәм яңарту турында тәкъдимнәр кертә, аның утырышларын алып бара, комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Комиссия рәисе булмаганда яисә аның кушуы буенча рәис вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

8. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә ярты елга бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

9. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карарлары Комиссия рәисе яки аның утырышта рәислек итүче урынбасары кул куйган беркетмәләр белән, утырыш уздырылган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек срокта рәсмиләштерелә.

Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы яки Башкарма комитеты карарын таләп итүче мәсьәләләр буенча тиешле тәкъдимнәр кертә.

Гомуми бүлек башлыгы: Г.Ф. Хәлиуллов